КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 706

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләрне формалаштыру турында» 2017 ел, 25 сентябрь, 715 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләрне формалаштыру турында» 2017 ел, 25 сентябрь, 715 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 декабрь, 966 нчы, 2018 ел, 11 апрель, 232 нче, 2018 ел, 21 ноябрь, 1026 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 71 һәм 72 пунктлар өстәргә:

«$7^1$. Әлеге карар Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларына (учреждениеләренә) кагыла дип билгеләргә.

$7^2$. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль оешмалар (учреждениеләр) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләр булдыру буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.»;

Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарлары исемлеген һәм күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары (учреждениеләре) өчен азык-төлек продуктларына ихтыяҗлар таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин